Хамитбаева Н.С., Багаутдинова Х.З. **Татарский театр на страницах газеты «Татарский телеграф» (1901-1905 гг.)** (на татарском языке)

Фэнни Татарстан. № 3. 2002, с.72-77

## "Казанский Телеграф" газетасы битләрендә татар театры мәсьәләләре (1901-1905 еллар).

Мәгълүм ки, Казанда профессиональ татар театры Россиядәге беренче революция елларында оеша. Әмма аның барлыкка килүе элегрәк чорларга ук карый. Бу процесс билгеле бер дәрәҗәдә XX йөз башындагы матбугатта чагылыш таба. Шул җәһәттән 1893 елның апрелennән 1917 елның мартына кадәр даими чыгып килгән "Казанский Телеграф" газетасы да әлеге мәсьәләгә игътибар бирә. Үзенең социаль юнәлеше белән газета реакцион-монархик позициядә тора. 1901-1905 елларның хронологик кысалары X1X йөз ахырында ук барлыкка килгән татар театры булдыру идеясенең акрынлап тормышка аша бару процессын үз эченә ала.

"Казанский Телеграф" газетасы үз сәхифәләрендә теге яки бу дәрәҗәдә татар мәдәни тормышының төрле якларын яктырта килә. Беренче чиратта ул Россия империясенең төрле төбәкләрендә, аерым алганда, Петербург, Симферополь, Баку, Ташкент һ.б. шәһәрләрдә мөселман (татар) җәмәгатьчелеге оештырган әдәби очрашулар, кичәләр хакында хәбәр итә. Болар гадәттә хәйрия кичәләре рәвешендә оештырылганнар. Мондый очрашуларның программасы нигездә төрле киносурәтләр тәкъдим итүдән, музыкадан, биюләрдән гыйбарәт булган. Мәсәлән, газета үзенең бер санында Симферополь каласында махсус мөселман клубы оешуы турында яза һәм анда төрле характердагы чыгышлар, очрашулар булуы хакында мәгълүмат бирә. Газета фикеренчә, Казанда да шундый эчтәлектәге җәмгыяте хәйрия булдырып, күп мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен очрашулар, бәхәс-әңгәмәләр оештырып җибәрү файдалы гамәл булыр иде. Моның белән беррәттән "Казанский Телеграф" татарлар арасында хәйрия җәмгыятьләренең эшчәнлеге сизелерлек җанлануын искәртә һәм алардагы аерым вәкилләрнең фәнни-популяр лекцияләр, халык укулары оештырып җибәрү өчен рөхсәт сорый башлауларын әйтә.

X1X гасырның беренче яртысында ук инде татарларның театр белән кызыксынулары хакында мәгълүматлар бар. Аерым алганда, М.С.Рыбушкин болай дип яза: "Татарлар вакытлар узу белән театрның иң кайнар яклаучыларына әверелделәр" (Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. - Казань, 1848, с.131). Шунысы игътибарга лаек, рус авторлары билгеләп үткәнчә, татар тамашачысы репертуарның асылын аңлап фикер йөртә, үз мөнәсәбәтен нигезле дәлилләр аша белдерә. Билгесез каләм иясе "Беренче адым" (1876) дип аталган җыентыкка урнаштырылган "Сәхнә әсәрләрен уңышка китерүче онытылган бер шарт" ("Забытое условие успеха сценических произведений") исемле мәкаләсендә, Казан театры тамашачысының шактый өлеше татарлар булуын күздә тотып, әгәр дә театр үз репертуарындагы бертөрлелектән котылырга теләмәсә, әнә шул контингентны югалту куркынычын исәпкә алсын дигән фикер уздыра.

Бу чорда Казанда татарча театраль тамашалар тыелган булганлыктан, рус шәһәр театрында мөселманнар өчен махсус спектакльләр оештырыла башлый. Шундый бер спектакль 1901 елның 27 январенда куела. "Казанский телеграф" хәбәр иткәнчә, татар тамашачысына "Бүреләр һәм сарыклар" ("Волки и овцы") дигән пьеса белән водевиль тәкъдим ителә, ә фойеда мандолиначылар оркестры уйный. Газета мәгълүматларыннан күренгәнчә, спектакль зур уңыш казана, аны дүрт йөзгә якын мөселман тамашачысы карый, Казан җәмгыяте хәйрия файдасына 760 сум акча җыела. Газета битләрендә спектакль хакында берничә җылы бәяләмә басыла һәм

татар тамашачысын беренче тапкыр масса күләмендә театрга тартуда зыялыларның, эшмәкәрләрнең, хезмәткәрләрнең, гомумән, төрле катлам вәкилләренең зур тырышлык куюлары әйтелә. Бәяләмәләрдә шулай ук, биниһая зур тырышлыклар куюга карамастан, татарча тамаша куюга рәсми рөхсәт алынмаса да, татар тамашачысын шул рәвешле театрга тартуда җәмгыяте хәйрия рәисе Заһид Шамилнең роле зур булуы искәртелә.

Татар җәмгыяте хәйрия файдасына куелган беренче спектакль Оренбург миллионеры Мәхмүт Хөсәеновны да кызыксындыра. Ул спектакльне оештыру эше, җәмгыяте хәйрия хакында җентекләп сораштыра. Шулардан чыгып, газета түбәндәге нәтиҗәгә килә: "Оренбургта да Казаннан үрнәк алырлар һәм тиз арада шундый ук хәйрия җәмгыятьләре оештырырлар дип ышанып әйтергә мөмкин" (Казанский Телеграф. - N2481. - 1901. - 18 февраль). Соңрак газета Оренбург татарларының шундый җәмгыять оештырырга рөхсәт сораган мөрәҗәгатьләренең кире кагылуын хәбәр итә. Генерал Барабаш бу позициясен мөселманнар үз омтылышларын инде яшәп килүче рус хәйрия җәмгыятьләре кысаларында тормышка ашыра алалар, шуңа күрә андый яңа оешмалар ачуга ихтыяҗ юк, дип аңлатырга тырыша.

Консерватив матбугатның үзенчәлеге шунда ки, ул хакыйкатьне бозу, фактларны буташтыру өчен төрле чаралар кулланса да, тышкы яктан объектив булып күренергә тырыша. Әйтик, газета оештыручыларның рус телендә генә спектакльләр куюын татарча репертуар юклыгы белән аңлата һәм ни өчендер татарча драма әсәрләренең X1X йөзнең 80 елларында ук барлыкка килүен "онытып" җибәрә. Билгеле булганча, Габдрахман Ильясиның бу өлкәдәге беренче тәҗрибәсе - "Бичара кыз" әсәре 1887 елда дөнья күрә. Бер ел да үтми, икенче драма әсәре - Фатих Халидинең "Рәдде бичара кыз"ы (1888) басыла. 1895 елда инде татар телендә комедия язу тәҗрибәсе ясала - билгесез авторның "Комедия Чистайда" китабы чыга. 1898 елда "Бәхетсез егет" драмасын язып, татар театры дөньясына Галиәсгар Камал беренче адымын ясый һ.б. Шуның белән бергә "Казанский Телеграф" үз-үзенә каршы килгән хәбәрләр дә урнаштыра: мәсәлән, ул 1901 елда Гаяз Исхакыйның "Өч хатын берлә тормыш" драмасын, 1903 елда "Ике гашыйк" комедиясе басылып чыгуы турында хәбәр итә.

"Казанский телеграф" газетасы Баку, Тифлис, Бакчасарай мөселманнарының театр-тамаша өлкәсендәге уңышларын билгеләп үтә. Ләкин шуның белән бергә бик тырышып Казан татарларының бу өлкәдә шактый артта калулары хакында кайта-кайта сөйли. Әйтик, 1904 елда газета яза: "Казан мөселманнары татар телендә спектакльләр оештыру белән эзлексез мәшгуль булган бер вакытта көньяк-рус губерналарындагы мөселманнар театраль тамашаларны зур уңыш белән тормышка ашыра киләләр" (Казанский Телеграф. - N3518.-1904. -22 сентябрь). Газета Казан татарларының сүлпәнлеген искәртә һәм театр тамашасы тормышларының инде аерылгысыз бер өлешенә әверелгән Кавказ мөселманнарына соклануын белдерә:"Җирле сөйләмдә куела торган спектакльләр биредә табигый хәл. Теге яки бу җирдә театр түгәрәкләре оеша, кайбер һәвәскәр артистлар хәтта сәхнәдә зур тәҗрибә туплаган актерлардан ким уйнамый. Эш шуңа барып җитте ки, "театраллар"ның үз партияләре дә барлыкка килде. Тамашачылар саны үсә, репертуарның һәркемгә аңлаешлы булуы һәм артистларның оста уены театрга чын мәгънәсендә халыкчан төс бирә" (Казанский Телеграф. - N3817. - 1905. - 25 сентябрь).

Көньяк төбәкләрендәге мөселманнарның театр өлкәсендәге уңышлары белән Казан татарларның гамәлләрен чагыштырып караган газета мәдәни үсеш өчен төрле районнарда төрле шартлар яшәвен игътибарыннан читтә калдыра. Эш шунда ки, X1X йөз уртасына кадәр патша хөкүмәте империянең үзәк районнарында яшәүче мөселманнарның мәнфәгатьләре белән билгеле бер дәрәҗәдә исәпләшергә мәҗбүр иде. Әмма X1X гасыр уртасыннан бу төбәкләрдә үз позициясен ныгытканнан һәм Идел буен тәмам яулап алынган районнар исәбенә кертә башлаганнан соң хөкүмәтнең

сәясәте кискен төстә үзгәрә. Ә бу үз чиратында мәдәни өлкәгә дә тәэсир итми калмый. Әле күптән түгел генә империя тарафыннан яулап алынган һәм башка дәүләтләр белән чиктәш территорияләрдә яшәүче мөселманнарга карата патша хөкүмәте йомшаграк сәясәт алып барырга мәҗбүр иде. Шуңа күрә дә ул бу җирләрдә яшәүче халыкларның әдәби-мәдәни үсешенә турыдан-туры тыкшынырга җөрьәт итә алмады. Димәк, "Казанский Телеграф" Казан татарларын артта калуда, сүлпәнлектә, битарафлыкта гаепләптә, бер үк вакытта Казанда татарча спектакльләр куюның рәсми рәвештә тыелуын әйтми калдырып, гамәлдә икейөзле сәясәт уздырылуын икърар итте. Мондый тыюлар татар җәмәгатьчелеген үз мәдәни ихтыяҗларын ярым яшерен шартларда үтәүгә этәрә, өй шартларында оештырылган тамаша-күренешләр белән канәгатьләнергә мәҗбүр итә иде.

Әнә шундый өй сәхнәсендә үз әсәрен куйган Г.Ильяси татар мәдәнияте тарихына беренче актер һәм режиссер буларак та кереп калган (Һ.Мәхмүтов, Г.Илялова, Б.Гыйззәт. Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан, 1988. - Б.29-31). Замандашлары раславынча, "Бичара кыз" драмасы язылу дәверендә үк инде сәхнәгә "күтәрелә". Спектакльнең 1898 елда Касыйм шәһәрендә куелуы хакында 1900-1909 елларда басылып килгән "Миръат" ("Көзге") җыентыгы хәбәр итә. 1900 елдан башлап татарча спектакльләр шәкертләр тарафыннан ярым яшерен төстә куела киләләр. Бу тамашалар гадәттә аерым фатирларда күрсәтелгән. Мәсәлән, Казанның иң алдынгы уку йортларыннан саналган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре, Казан Укытучылар мәктәбендә куелган русча спектакльләр белән таныш буларак, милли телдә дә театр уйнау мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Озак бәхәсләрдән соң "артистлар" Г.Камалның "Бәхетсез егет" драмасына тукталалар. Репетицияләр яшерен рәвештә "Сарай" кунакханәсенең бер бүлмәсендә оештырыла. Спектакльне куяр өчен сәхнә дә булмый. Әмма шәкертләр югалып калмый, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең өченче каттагы коридорын сәхнә итеп ала һәм спектакль 1903 елның 30 октябрендә тамашачы хозурына җиткерелә. Шәкертләрнең эшчәнлеге моның белән генә чикләнми, алар әдәби-музыкаль кичәләр оештыралар, яңадан-яңа тамашалар әзерлиләр. Аерым энтузиастларның эшчәнлеген тагын да нәтиҗәлерәк һәм мәртәбәлерәк хәрәкәткә әверелдерү тора-бара заман таләбенә әйләнә. Шул максаттан чыгып, "Шимбә" түгәрәге оеша. 1904 елның 18 гыйнварендә Беренче тау (Первая гора) урамындагы (хәзерге Ульяновлар урамы) Габитовлар йортында "Шимбә" түгәрәгенең беренче спектакле күрсәтелә. Репертуар өчен төрек теленнән тәрҗемә ителгән "Кызганыч бала" драмасы белән "Гыйшык бәласе" исемле комедия сайланып алына. Бу хәл Тифлистә чыгучы "Шәркый рус" газетасына да мәгълүм була һәм уңай бәяләмәләр ала. 1904 елның 4 апрелендә подполковник Сәхәб Еникеев фатирында куелган "Гыйшык бәласе" спектаклен карарга күп кенә тамашачы җыела, һәм бу кичә зур бер вакыйгага әверелә. 1904 елда "Казанский Телеграф" шундый эчтәлектәге хәбәр урнаштыра: Казанда һәвәскәр мөселман артистларының үз түгәрәкләре ныклап оеша һәм алар хәйрия җәмгыятенә үз ярдәмнәрен күрсәтү тәкъдиме белән дә мөрәҗәгать итәләр, әмма җәмгыять әгъзалары бу ярдәмнән баш тарта, шунлыктан оештырылган спектакль куелмый кала. Газета бу хәлгә гаҗәпләнеп, "ни өчен?" дигән сорау куя. Ләкин шул ук вакытта янә бер кат татар телендә рәсми тамашалар патша хөкүмәте тарафыннан тыелган икәнлеген "онытып җибәрә".

"Казанский Телеграф" фикеренчә, татар театрын тормышка ашыруда репертуар булмаудан тыш, хатын-кыз ролен башкаручыларның юклыгы да зур кыенлык тудыра. Бу проблемага газета зур игътибар бирә. Мәсәлән, 1902 елда Казанда татарча спектакль куелу мөмкинлеген күздә тотып, ул күп кенә кешеләрнең моңа шик белән карауларын әйтә. Сәбәбе ачык: татар хатын-кыз ролен уйнаучылар юк, шуңа күрә чын мәгънәсендә спекткаль кую идеясе якын арада гына тормышка ашмаячак. Газета әлеге фикерне үстерү ниятеннән "әзәрбайҗан татарлары" (газета гыйбарәсе) турында болай дип яза:

"Көньяк өлкәдә татарча спектакльләр куела. Анда мөселман кызлары да катнаша. Ләкин аларны гастрольгә Казанга чакырып булмый бит инде". (Казанский Телеграф. - N2934. - 1902. - 4 октябрь).

Газета театр училищеларында мөселман кызларының саны артсын иде дигән теләк белдерә. Шул ук вакытта түбәндәге шәрехләүне кирәк таба:"...без бары тик мөселман кызларын гына күздә тотабыз, чөнки әгәр дә алар махсус театр мәктәбен узалар икән, бу аларны гомер буена сәхнә тормышына табынучы итеп тәрбияләячәк, ә бу очракта инде бернинди хөрафатлар да ул җаннарны сәнгатькә омтылышларыннан туктата алмаячак" (Казанский Телеграф. - N 2934. - 1902. - 4 октябрь). Бер яктан, газета хаклы фикер йөртә һәм иске гореф-гадәтләрнең театр үсешен тоткарлаулары турында әйтә. Әмма шул ук вакытта мәгълүм үзгәрешләр булуын да таный һәм мөселман хатын-кызларының тамашачы ролендә булулары гадәти күренешкә әверелде дип раслый. "Кайбер мөселман кызлары, - дип яза газета, - театрга киләләр һәм йөзләрен яшерми утыралар. Бу хакта карт мөселманнар да белә, әмма алар тарафыннан театрга йөрүче мөселман кызларын шелтәләү һич тә ишетелми". (Казанский Телеграф. - N 3199. - 11 сентябрь). Икенче яктан, биредә башка, яшерен ният тә салынган. Газета гүя бу вакытта әле Россиядә татар театрларының да, татар театр училищеларының да юклыгын "истән чыгара". Ә инде татар яшьләрен рус уку йортларына чакыру ул чорда бары бер максатка - хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтенә хезмәт итә иде. Әгәр дә газета нәкъ менә мөселман кызларына аеруча игътибар бирә икән, бу да очраклы хәл түгел. Власть әһелләре хатын-кызның киң катлау татар халкы арасында рус теленең ролен ныгытуына исәп тота, шуңа күрә дә белем бирүнең бөтен мөмкинлекләреннән тыш, сәнгать чараларыннан, шул исәптән театрдан да файдалануны кулай күрә.

Х1Х йөзнең беренче яртысында ук инде М.С.Рыбушкин театрның хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтендә бер алым икәнен искәртеп узган иде. "Казанский Телеграф" та дәүләт сәясәтенә теләктәшлек күрсәтеп, татар тамашачысын күз уңыннан ычкындырмаска тырыша. Мәсәлән, 1902 елның 6 декабрендә шәһәр театрында "Ревизор" спектакле куелуын хәбәр итеп, газета анда татарларның, аеруча укучы яшьләрнең күп килүе турында яза. Газетаны алар арасында бигрәк тә 30 га якын мәдрәсә шәкерте булу факты куандыра. Мәкалә авторы билгеләп узганча, гадәттә шәкертләр, рус телен белмәү сәбәпле, рус шәһәр театрында бик сирәк күренүчеләрдән санала.

Газетаның шәһәр театрына йөрүче татарлар белән кызыксынуы А.М.Горькийның "На дне" спектакле куелу уңае белән басылган язмасында ачык күренә. Спектакльнең үзе турында мәкаләдә берни дә әйтелми, аның каравы залдагы арзанлы урыннарның бик уңайсыз урнаштырылуы һәм бу хәлнең театрга беренче тапкыр килгән татарларның гайрәтен чигерү мөмкинлеге хакында иркенләп гәп сата. Газета кыйммәтле урыннарның татарларга бөтенләй эләкмәве өчен дә борчылуын белдерә. Бер уйласаң, нинди соклангыч кайгырту! Әмма бу гамәлнең асылында әлеге дә баягы шул руслаштыру сәясәте ята.

"Казанский Телеграф" Казандагы Татар укытучылар мәктәбенә дә зур игътибар бирә. Газета хәбәрләреннән күренгәнчә Укытучылар мәктәбе укучылары шәһәр театрына еш йөргәннәр. Мәсәлән, газета Сухово-Кобылин пьесасы буенча куелган тамашада барлык ложаларда шыплап тулган укучы яшьләр арасында Татар укытучылар мәктәбе вәкилләренең дә күп булуларын билгеләп үтә. Бу "татар гимназиясе"ндә укучыларга театр дирекциясе чакыру билетларын юмарт рәвештә тарата торган булган. Газета бик тәфсилләп Укытучылар мәктәбендә 21 февраль көнне Н.В.Гогольгә багышлап кичә уздырылуы хакында да яза. Кичәдә мулла Яхин һәм мәктәпнең инспекторы М.Н.Пинегин чыгыш ясый. Барлык укучы яшьләргә Гоголь әсәрләре таратыла, әдипнең "Сорочинская ярмарка" әсәре тыңлана. 23 февраль көнне ике комедия - "Дядька в затруднительном положении" ("Абзыкай авыр хәлдә"), "Игроки"

("Уенчылар") уйнала. Рольләрне башкаручылар мәктәпнекеләр була һәм, газета язганча, уен шыгрым тулы залны тыелгысыз көләргә мәҗбүр иткән. Спектакльгә уку-укыту округы попечителе ярдәмчесе А.А.Остроумов һәм округ инспекторы

Н.Ф.Свешниковлар килә. Бу билгеле бер мәгънәдә Татар Укытучылар мәктәбендә белем алучыларның русча белү дәрәҗәләре белән кызыксынуга дә бәйле. "Ревизор" спектакле хакында сүз алып барганда, газета рольләрне уйнаучы укучыларның русча сөйләшүләре әйбәт кенә булуын билгеләп үтә, ә кайберләрнеке, гомумән, мөкәммәл дип раслый. Спектакльдә уку-укыту округы җитәкчесе үзе дә катнаша.

Татар Укытучылар мәктәбендә оештырылган кичәләр, спектакльләр турында сүз алып барганда газета ул мәдәни чараларда тамашачылар күп булуына, шул исәптән кызлар да күренүенә дикъкать итә. Әмма иң мөһиме, газета фикеренчә, ул кичә һәм спектакльләрдә мәдрәсә шәкертләренең очравы. Алар өчен бу хәл эзсез узмый дип фикер куерта газета һәм "димәк ки, Укытучылар мәктәбенең кечкенә театры шәкерт белән зур шәһәр театры арасында күпер ролен үти", дип нәтиҗә ясый. Алга китеп, газета мондый арадашчылыкның асылын да ача - ул "рус телен өйрәнүдә ярдәмчел чара" (Казанский Телеграф. - N 3294. - 1904. - 14 январь). Болардан аңлашылганча, төп максат татарларга рус әдәбияты һәм сәнгать дөньясының байлыгын ирештерү түгел, ә хөкүмәтнең мәгълүм руслаштыру сәясәте икән. Шуннан чыгып, газета мәдрәсә шәкертләренең театраль тамашаларга йөрүе зарур, дигән фикер уздыра, бер үк вакытта муллалыкка имтихан тотучыларның рус телен белүләре мәҗбүри икәнлегенә басым ясарга да онытмый.

Газетаның татар тамашачысына булган асыл мөнәсәбәте билгеле бер дәрәҗәдә Кавказдагы Шуша шәһәрчегендә куелган спектакльгә багышланган язмасында ачык күренә. Биредә Шекспирның "Отелло" трагедиясе уйнала һәм, газета хәбәр итүенчә, театр шыгрым тулы була. Спектакль тамашачыга шул кадәр нык тәэсир итә ки, Дездемонаның үлеме вакытында бөтен зал күз яшьләренә күмелә. Антракт вакытында тамашачылар Отелло ролен уйнаган артистны чакырып аңа рәхмәт белдерәләр, ә спектакль бетүгә "Отелло"ның барлык нөсхәләрен сатып алып бетерәләр. Дөнья драматургиясенең бөек әсәрен татар тамашачысының шулай кабул итүе (әлбәттә, бу хис башка халыкларга да хас) - табигый һәм аңлаешлы. Әмма мәкалә ахырында автор болай ди: "Без татарларга артта калган, безнең аңлау, кабул итү дәрәҗәбезне тоемлауга сәләтсез кавем дип карарга күнеккәнбез. Һәм нәрсә күрәбез? Бөек Шекспир үзе бу надан татар тамашачысына аңлаешлы булып чыкты. Ул Дездемонаның газаплары һәм үлеменә яшь түкте, Отеллоны кызганды һәм Ягоны каргады..."(Казанский Телеграф. - N 3518. - 1904. - 22 сентябрь). Бу язманы "Казанский Телеграф" "Новости" газетасыннан (фельетон авторы - Г.С-в) күчереп бастыра һәм моны янә бер кат Казан мөселманнарының спектакльләр оештырудагы сүлпәнлеген ассызыклау өчен файдалана. Бер карасаң, "Казанский Телеграф" изге нияттә тора һәм Казан татарларын үз театрларының булдыруга активрак керешүләрен тели кебек. Әмма игелеклелек битлеге астында үтә тар карашлы типның чын йөзе, аның шундый ук борынгы, шундый ук бай, әмма үзенә билгесез булган мәдәнияткә масаючан мөнәсәбәте яшеренгән. Бу хәлгә, мәгълүм булганча, бүтән халыкларның мәдәниятен өстән-өстән генә белү этәрә. Монысы исә, үз чиратында, үзеңне башкалардан бик югары кую теләгенә һәм үз мәдәниятеңне аларга көчләп тагу ниятенә китерә. Гыйбрәтле мисал: Казан университеты профессоры Корсаков "Бөек рус кавеменең Шәрыкъка алгарышлы хәрәкәте һәм аның тарихи әһәмияте" исемле докладында шундый сүзләр әйтә:"Безнең мәдәният аларныкыннан өстен, шуңа күрә без алар арасына рус культурасы белән ассимиляцияләүче православиене таратабыз" (Казан, 1889, б.49). Православие төшенчәсе астында рус мәдәниятенең бөтен җыелмасы күздә тотыла булса кирәк.

Татарларны артталыкта һәм сүлпәнлектә гаепләүләр Казан мөселманнарын татар театрын булдыруда активрак эш итәргә этәргән дип тә уйларга мөмкин. Бу очракта "Казанский Телеграф" газетасының уңай ролен, әлбәттә, билгеләп үтәргә кирәк. Моннан тыш, газета Россиянең башка шәһәрләрендә куелган спектакльләр хакында хәбәрләр биреп, ихтыярсыз татар театрының Казанда да барлыкка килүенә каршы киртәләрне беркадәр какшатуга ирешә.

Газета язмаларын күзәтеп чыкканнан соң шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: хөкүмәт татар халкы арасында театр сәнгате таралуын бик игътибар һәм саклык белән күзәтеп бара, бу хәрәкәтне мөмкин кадәр руслаштыру сәясәте агымына кушып җибәрүгә дикъкать бирә. Шуның белән бергә газета хәбәрләреннән татар театры үсешен тоткарлауга юнәлтелгән ысулларның җәмәгатьчелек фикерен булдыруда файдаланылуы сизелә. Татар театры проблемасына мөнәсәбәтендә газетаның либераль битлек астында бик нык яшерелгән шовинистик асылы ачыла. Шуңа күрә материалларны биргән вакытта газета чынбарлыкның бары бер өлешен генә күрсәтә, ә чын сәбәпләр нигездә яшерелеп калдырыла.

Шушы җитешсезлекләргә карамастан рус телендә чыккан "Казанский Телеграф" газетасы татар театры үсешен өйрәнү буенча кызыклы гына мәгълүматлар бирә. XX гасырның беренче елларында татар театры үсешенә үзенчә игътибар бирүе белән ул безнең өчен матбугат органы гына түгел, тарихи чыганак буларак та әһәмияткә ия.